СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«НОВОЧЕРШИЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЯҢА ЧЫРШЫЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2024 елның 4 октябре № 22

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында «Федераль законның 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 30.05.2017 № 6, 17.11.2017 № 22, 29.01.2018 № 1, 19.09.2018 № 25, 14.12.2018 № 41, 22.01.2019 № 1, 20.03.2019 № 6, 02.10.2019 № 25, 12.02.2020 № 1, 17.06.2020 № 10, 13.08.2020 № 11, 12.11.2020 № 13, 26.03.2021 № 5, 10.08.2021 № 21, 28.04.2023 № 19, 01.08.2023 № 25, 23.10.2023 № 37, 18.12.2023 № 45, 25.04.2024 № 7 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәреш кертергә:

10 нчы бүлекнең 10.1.3 нче пунктының 5 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) белем һәм квалификация турында документ».

2. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Яңа Чыршылы авылы, Заречная ур.,25 йорт, Үзәк ур.,12А йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru), «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам

Лениногорск муниципаль районы
"Яңа Чыршылы авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

Р.Ә. Мөхәмәтшина